# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге составына керүче Левашево авылы

№ 2

13 ноябрь 2019 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге составына керүче Левашево торак пунктында гражданнар җыены

**карар итте**:

1.2020 елда Левашево авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- җирлекэчендәге юлларны караптоту;
- контейнер мәйданчыкларытөзү;
- чүп контейнерлары сатыпалу һәм урнаштыру.

3.Әлеге карарны Левашево авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче С.А.Демидова